ГАИ ГАИ ГАИ

# Бер минутны отам дип...



Тимер юл кичүләре аша хәрәкәт куркынычсызлыгы мәсьәләсе ГАИ бүлегендә күп мәртәбәләр кузгатылды инде. Әмма ул проблема бүген дә актуаль булып кала бирә, чөнки тимер юл аркылы ничек тә тизрәк, хәтта килүче поезд алдыннан ук та чыгып калырга тырышучылар очрап тора. Югыйсә бит Россиядә тимер юл кичүендә ел саен 500ләп фаҗига булып, аларда 800ләп кеше үлүе яки җәрәхәтләнүе һәм бу санның поездлар һәлакәтләрендә үлүчеләр саныннан дистәләрчә тапкыр күбрәк икәнлеге мәгълүм.

Дөрес, кызыл ут янып торып та, поезд тиз генә килмичә, озак көтәргә туры килгәли. Әмма тәртип бозуларны бу гына аклый алмый.

Менә быелның ике аенда гына да Норлаттагы 1077 нче километрдагы кичүдә аны ябык көенә 7 аркылы чыгу очрагы теркәлде. Кагыйдә бозучылар арасында В.Н.Трофимов («Агрохимсервис»), И.А.Тимбиков (МСО АТПсы), В.А.Наумов (УТТ), Х.Г.Якупов (суд), Р.Г.Әхмәдиев (УТТ) һәм башкалар бар. Үз машинасындагы пенсионер Ф.А.Пискунов та авария очрагы китереп чыгара. Ул аздан гына поезд астына эләкми кала. Составны экстерн рәвештә туктатырга туры килә.

Шулай булгач, берәр минутны отарга тырышып, гомереңне куркыныч астына кую кирәкме икән соң? Әле бит башкаларга да зур куркыныч яный, поездлар хәрәкәте дә катлаулана. Әле матди зыян китерүчеләр дә бар. Әнә, «Беларусь» тракторы белән билгесез бер тракторчы шлагбаумны ватып киткән.

Алда телгә алынган тәртип бозучыларның барысына да минималь хезмәт хакы күләмендә штраф салынды.

Хәрәкәт иминлеге өчен көрәш рульдәгеләрнең дә, ГАИ хезмәткәрләренең дә уртак эше булырга тиеш. Шул җөмләдән тимер юл кичүләрендә дә.

**Х.ӘЮПОВ,**
**ГАИ бүлеге начальнигы, милиция майоры.**

*Газета - укучы - газета*

## ӨМЕТЕМНЕ ӨЗМИМӘЛЕ

Телефон кертүләрен 15 ел көтәм инде. Беренче гаризамны 1982 елда язган идем. Гел вәгъдә итеп килделәр. Түрәләр алышынды, вәгъдәләр кала бирде. 1992 елның маенда тагын бер өмет уты кабынган төсле иде: ул чакта Татарстан хөкүмәтенең 1991 ел, 28 декабрь карары белән телефон займы чыгарылды. Шул чакта беренчеләрдән булып 3 мең тәңкә түләдем мин.

Шуннан соң да вәгъдә иттеләр. Әмма үтәргә генә ашыкмыйлар. Инде яңа заем чыкты. Ә искесе өчен кем җаваплы икән соң? Район элемтә бүлеге җитәкчелегеннән шул хакта ишетәсе иде.

**Анатолий Павлович ЯКУНИН.**
**Норлат шәһәре.**



*Кыш.*

Н.АЗИЗОВ фотоэтюды.

## ЯРДӘМЕГЕЗГӘ МОХТАҖБЫЗ, ЯКТАШЛАР

Мин Яңа Әмзәдә туып үстем. Туган төбәгемдәге «Хуҗалар тавы» дип аталган гаҗәеп матур табигать һәйкәле белән гомерем буе горурланып яшәдем. Анда барып кайту җанны сихәтләндерә, шифалы суын татып карагач яшәүгә өметем арта иде. Изге чишмә суын эчеп дәва алырга дип Биләргә баручы кешеләрнең бер вакытта да юллары үкенечле булмады.

Бу язмамда бөек Биләр шәһәре тарихын язып тормасам да, аны күпләр белә булыр. Биләр шәһәре хәрабәләре астында әби - бабаларыбызның изге сөякләре, әлегәчә ачылмаган тарих сәхифәләре ятуы да барыбызга да билгеле. Сүзем исә бүген башка нәрсә хакында. Без, шул төбәктә туып үсеп һәм хәзер Чаллыда яшәүче бер төркем кешеләр, «Биләр фонды» оештырырга булдык. Фонд Яр Чаллы шәһәре хакимияте карары нигезендә рәсми теркәлде. Аның идарә советына Рифкать Курмашев (Аксубай районының Шәрбән авылында туган), Айрат Кәбиров (Дума), Әмир Гайнуллин, Рәмзис Миндубаев (Колбай Мораса), Графит Ибәтуллин (Яңа Әмзә) керә. Фондның үз алдына куйган бурычы борынгы Биләр шәһәре һәйкәлләрен торгызу һәм саклау, бу территориядә археологик казу, реставрация эшләре үткәрү, шул чорга гына хас җитештерү ысулларын торгызу, Биләргә бәйле реклама, басма эшләрне башкарудан гыйбарәт. Узган елның 26 ноябрендә Чаллы шәһәрендә «Биләр шәһәре: үткәне һәм хәзергесе» дигән темага түгәрәк өстәл артында сөйләшү үткәрелде. Анда Чаллы, Казан шәһәрләрендә яшәүче тарихчылар, археологлар катнаштылар, фикер алыштылар.

Бу очрашуны үткәрүдә Чаллы педагогия институты ректораты һәм студентлары актив катнаштылар.

Фонд алдына куелган мәсьәләләр шактый күп һәм катлаулы. Аларны хәл итү зур финанс чыгымнары таләп итә. Шуңа да фонд идарәсе Аксубай, Алексеевск, Әлки, Чирмешән, Чистай һәм башка районнарның оешма, предприятиеләр, аерым эшмәкәрләре һәм башкалардан фонд эшендә катнашуларын, икенче төрле итеп әйткәндә, матди ярдәм күрсәтүләрен сорый. Фондның адресы: Яр Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Гидростроительләр урамы, 21 нче йорт, тел.: 42 - 25 - 75.

Камкомбанктагы агымдагы счет 700161685 / 700434, Чаллыдагы «Ак Барс» банкы бүлекчәсендәге счет № 700574.

**Нургаяз СӘЛАХОВ.**
**«Биләр» фонды идарәсе рәисе.**





Ветеринария табибы Галина Якшина дүрт аяклы пациентының ашказаныннан 36 см озынлыктагы пычак тартып чыгара. Бакса кушаматлы өч айлык бу эт баласының хуҗасы әйтүенә караганда, ул өстәлдән ашамлык салынган тәлинкәне тартып төшерә. Озак та үтми, авыртудан чинап җибәрә. Хуҗа җентеклебрәк карый торгач, аптырап кала: тәлинкәдәге пычак күренми. Хәерлегә түгел бу, дип, этне ветеринарга алып бара. Чыннан да пычак эт баласының корсагында булып чыга. Буе нибары 50 сантиметрлы бу мәхлук ничек шундый озын пычакны йота алган - шунысы гаҗәп.

### Пычак йоткан эт баласы

### Үлгәч тә анада бала кайгысы

«Бу хәл 1979 елда булды. Мин ул чакта Көнчыгыш Себер тимер юлында товар поезды машинисты булып эшли идем. Вихоревск шәһәренә җитәрәк (Братскидан 40 чакрым чамасы) мин дә, ярдәмчем дә юл уртасында басып торган хатынны күрдек. Ул составны туктатуны үтенеп, кулларын болгый иде.

Аерым очракларда гына рөхсәт ителә торган тормозга бастык. Ата - бабасын телгә алып сүгенә - сүгенә кабинадан чыктык. Ә ул тыныч кына гафу үтенеп, борылыштан арырак ике баланың - малай һәм кыз баланың - рельста ятуын әйтте. Ә үзе кире борылып, урманга агачлар арасына кереп югалды.

Гаҗәпкә, ул әйткән урында чыннан да йоклап яткан балаларны таптык. Уятырга теләсәк тә, уята алмадык. Аларны беренче торак пунктына барып җиткәч тә милиция бүлегенә тапшырдык.

Берникадәр вакыттан соң безне тикшерүче эзләп тапты. Берничә фоторәсем күрсәтте. Шуларның берсе безгә очрап, фаҗигане булдырмый калган хатын сурәте иде. Ул хатынның - әлеге балалар анасының моннан инде 3 ел элек үлгәнен әйткәч, без телсез калдык. Бу җинаятьнең тарихы коточкыч: балаларның әтисе икенче тапкыр өйләнә, үги ана балаларны күрәлмый, һәм менә ул ирен, әлеге балаларга йоклаткыч дару биреп, аларны рельска куярга ризалаштыра. Янәсе, «гөмбәгә киткәннәр иде дә кайтмадылар».

Җинаять ачылса да суд булмый кала. Ата кеше вөҗдан газабыннан үз - үзен үтерә. Үги ананың гаебен раслый алмыйлар. Иң гаҗәбе шунда: әлеге өрәк безнең поезд алдына тагын килеп басмасынмы. Без тагын поездны туктаттык. Кабинадан чыктык. Ул балаларны коткарган өчен безгә ихлас рәхмәтен әйтте. Аңа җавап бирә алмадык, тамакка төер утырган иде.

Ул, борылып, кабат урманга таба китеп барды. Бу юлы шунысы хикмәтле: икенче очрашуыбыз кыш көне булды. Җирне кар каплаган иде. Әлеге хатын артыннан кар өстендә бернинди эз калмавы безне аеруча гаҗәпләндерде. Әлеге вакыйгага чаклы мин дәһри булсам, моннан соң дингә ышана башладым».

**(«Мәдәни җомга»дан).**


*Белдерүләр*

**Сатабыз**



**Тимер юл кичүе янында капиталь гараж.** Адрес: Толстой ур., 8 (кичке 6дан соң).

***

**1987 елгы, әйбәт хәлдәге «Комби» Москвич автомобиле.** Самара өлкәсе, Кошка районы, Иске Кармала авылында Николай Ильич Плешаковка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Т-40 тракторы, арбасы.** Адрес: Кормыш пос., Дружба ур., 21.

***

**Западный микрорайонында бөтен уңайлыклары булган, 5 бүлмәле, 145 кв. метрлы йорт. Йортта сауна һәм бассейн, янында 12 сутый бакчасы, 2 автомашиналык гараж, тимер белән эчләнгән баз, каралты - курасы бар.** Тел.: 65 - 3 - 11.

***

**Әфган поселогында кирпеч йортны ашыгыч төстә, мунчасы бар.** Тел.: 5 - 25 - 76.

**Фатир эзлибез**

**Бер бүлмәле фатир эзлим, базар тирәсендә һәм беренче катта булса яхшырак. Түләү килешү буенча.** Тел.: 5 - 11 - 58.

***

**Фатир эзлибез.** Тел.: 5 - 24 - 29.

***Октябрь урман хуҗалыгы ОРСы ваклап һәм түмәрләп:***

**СМД - 20гә пешкәк группасы (бер компл[illegible] 1.900.000 сум).**

**Д - 240 ка пешкәк группасы (комплекты 1.900.000 сум).**

**Сырган курткалар (данәсе 90.000 сум) сата.**

Түләү төрле формада. Адрес: Лесосклад ур., 2, урман хуҗалыгы ОРСы, тел.: 2 - 26 - 17.


Норлат типографиясе һәм «Дуслык» район газетасы редакциясе коллективлары ире **Мингаяз Нурулла улының** вафат булуы сәбәпле типографиянең элеккеге хезмәткәре Саимә Нургали кызы Мөхәммәтҗанованың авыр хәсрәтен уртаклашалар.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2071 данә. Заказ № 5738